Tatar - Изге Язманың - Soul Scriptures

Маттай 11:28-30 Авырлыктан җәфа чигүчеләр, һәммәгез дә Миңа килегез. Мин сезгә тынычлык бирермен. 29 Минем камытымны үзегезгә киегез һәм Миннән өйрәнегез, чөнки Мин – юаш, басынкы күңелле; һәм сез тынычлык табарсыз. 30 Чөнки Минем камытым уңайлы һәм йөгем җиңел!

Башта - Бытие 2:7 Раббы Иеһова адәмне туфрактан яратты һәм аның борын тишекләренә тереклек сулышы өрде. Адәм әнә шулай җан иясе булды.

1 Патшасы - 3 Патшалар 1:29; Зәбурда 23:3; 34:22; 69:18 - Иеһоваһ restore soul - Лүк 1:79 Караңгыда һәм үлем шәүләсендә утырганнарга яктылык бирү өчен, Аякларыбызны тынычлык юлына юнәлтү өчен киләчәк Ул.

Хизәкил 13:20,21 Шуңа күрә Хуҗа-Раббы болай дип әйтә: «Кош аулаган сыман, җан аулау өчен теккән сихер бәйләвечләрегезгә каршы чыгып, аларны кулыгыздан йолкып алам һәм, сез кош аулаган сыман, аулаган җаннарны ирекккә җибәрәм. 21 Бөркәнчекләрегезне ертып ташлап, халкымны сезнең кулдан йолып алам, алар инде сезнең табыш булмас; һәм Минем Раббы икәнемне белерсез.

Маттай 10:28 Тәнне үтереп тә, җанны үтерә алмаучылардан курыкмагыз. Бәлки күбрәк җәһәннәмдә җанны да, тәнне дә һәлак итә алучы Иеһоваһыдан куркыгыз!

Маттай 16:26 Бөтен дөнья милкен үзенә алып, җанын һәлак итсә, кешегә моннан ни файда? Ул, үзенең җанын кире кайтарып алыр өчен, нәрсә тәкъдим итә алыр икән соң?

Маттай 22:37 «Раббы Иеһоваһыңны бөтен йөрәгең, бөтен җаныңны һәм бөтен акылыңны белән ярат», – диде Гайсә.

Маттай 26:38 Ул аларга: – Минем җаным чиктән тыш газап кичерә, монда көтегез һәм Минем белән бергә уяу булыгыз! – диде.

Марк 8:36,37 Әгәр берәү бөтен дөнья милкен үзенә алып, җанын һәлак итсә, моннан аңа ни файда? 37 Кеше нәрсә биреп үзенең җанын кайтарып ала алыр икән?

Марк 12:30 Раббы Иеһоваһыңны бөтен йөрәгең, бөтен җаныңны, бөтен акылыңны һәм бөтен көчең белән ярат».

Марк 12:33 «Аны бөтен йөрәгең, бөтен уйларыңны һәм бөтен көчең белән ярату» һәм «Якыныңны үзеңне яраткан кебек ярату» бөтен

корбан итеп чалынган хайваннардан да һәм корбан итеп яндырылган бүләкләрдән дә мөһимрәк. (Второзакониа 4:29)
Марк 14:34 Гайсә аларга әйтте: – Минем җаным чиктән тыш газап кичерә, монда көтегез һәм уяу булыгыз!
Лүк 12:20 Әмма Иеһоваһы аңа әйткән: «Әй, син, акылсыз! Шушы төндә тормышыңны синнән кире алачаклар. үзең өчен җыйганнарың кемгә калыр соң?»
Лүк 21:19 Чыдамлыгыгыз белән тормышыгызны коткарырсыз.
Яхъя 12:27 Күңелем Минем хәзер борчулы. Нәрсә әйтим? «Атам! Мине бу сәгатьтән коткар!» – дипме? Ләкин бу сәгатькә Мин нәкъ шуның өчен килдем дә.
Рәсүлләр 14:22 Шәкертләрнең күңелләрен дәртләндереп, иманда нык торырга өндәделәр. – Иеһоваһы Патшалыгына керү күп михнәтләр аша булачак, – диделәр.
Рәсүлләр 15:24 Бездән килгән кешеләр, без аларга шундый эшне тапшырмаган булсак та, сезне борчыганнар һәм күңелегезне тынычсызлаганнар дип ишеттек.
1 Көринтлеләргә 15:45 Изге язмада болай дип язылган: «Беренче кеше – Адәм – тере җан иясе булды»; ә соңгы Адәм – тормыш бирүче Рух.
1 Тессалуникәлеләргә 5:23 Иеһоваһы үзе, тынычлык чыганагы, сезне бөтен килеш изге итсен. Раббыбыз Гайсә Мәсих килгәндә Ул бөтен барлыгыгызны: рухыгызны да, күңелегезне дә, тәнегезне дә саф килеш сакласын.
Еврейләргә 6:19 Бу өмет безнең җаныбызның ышанычлы вә ныклы якоре сыман. Ул пәрдә артындагы Иң изге урынга керә.
Еврейләргә 10:39 Ләкин без иманнан баш тартып һәлак булучылардан түгел, юк, без иманда торабыз һәм коткарылачакбыз.
Ягъкуб 1:21 Шулай итеп, бөтен әхлакый шакшылыктан һәм башка төрле яманлыктан ваз кичегез, йөрәкләрегез туфрагына утыртылган Иеһоваһы сүзен тыйнаклык белән кабул итегез, ул сүз сезнең җаннарыгызны коткара ала.
Ягъкуб 5:20 ул вакытта белегез: гөнаһлыны ялган юлыннан кире кайтаручы кеше бу гөнаһлының җанын үлемнән коткарыр һәм күп гөнаһларның кичерелүен тәэмин итәр.
1 Петер 1:8/9 Гайсә Мәсихне күрмәгән килеш яратасыз, хәзер күрмәсәгез дә, Аңа иман итәсез һәм иманыгызның максатына, җаныгызның котылуына ирешеп, әйтеп бетергесез һәм ифрат зур куаныч белән шатланасыз.
1 Петер 1:22 Хакыйкатькә итагать итеп, җаннарыгызны пакьләдегез

 һәм хәзер имандашларыгызга риясыз мәхәббәт күрсәтәсез. Шулай булгач, бер-берегезне ихлас күңелдән яратыгыз!

1 Петер 2:11 Сөеклеләрем! Сездән, килмешәкләрдән һәм мосафирлардан үтенәм: һанга каршы көрәшүче гөнаһлы теләкләрдән читләшегез;

1 Петер 4:19 Шулай итеп, Иеһоваһы ихтыяры буенча газап чигүчеләр үз һаннарын тугры Тудыручыга тапшырсыннар һәм игелек кылуларын дәвам итсеннәр.

2 Петер 2:7,8 Анда яшәгән азгыннарның әхлаксыз гамәлләреннән интеккән әхлаклы Лутны коткарган. 8 Бу әхлакый кеше азгыннар арасында яшәгәндә, аларның әхлаксыз эшләрен күреп һәм ишетеп, чын күңеленнән көннән-көн газап чиккән. (Хөкем 16:16)

3 Яхъя 1:2 Сөекле дустым, һаның уңышка ирешкән кебек, һәрьяктан да имин һәм сәламәт бул, дип дога кылам.

Башта - Бытие 34:2,3,8 Shechem's soul tie to Dinah.
Саны 21:4 soul discouraged.
1 Шамуил - 1 Патшалар 18:1 friend soul tie.
2 Патшасы - 4 Патшалар 4:27; Әюбнең 19:2; Зәбурда 6:3,4 soul vexed.
Әюбнең 7:11 bitter soul.
Әюбнең 14:22 soul mourn.
Әюбнең 27:2 grieve soul.
Зәбурда 41:4 Иеһоваһ heal soul.
Зәбурда 42:5,6,11; 43:5 disquieted soul hope in Иеһоваһ.
Зәбурда 97:10 Иеһоваһ keep soul safe.
Зәбурда 107:9 longing and hungry soul.
Зәбурда 119:28 heavy soul melt, Иеһоваһ strengthens.
Зәбурда 120:2 Иеһоваһ deliver from bad words.
Зәбурда 121:7 Иеһоваһ preserves soul.
Зәбурда 138:3 Иеһоваһ strengthens soul.
Кинаяләр 6:32 adultery destroys soul.
Кинаяләр 22:24,25 angry man snares soul.
Иремия 31:25 Иеһоваһ satiate weary soul, and replenish sorrowful soul.

Pastor T. John Franklin
Church of Salvation, Healing, and Deliverance
COS-HAD.org